ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮҢГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район д. Нижние Шаши Тел. 3-60-38

**КАРАР № 85**

**Түбән Шашы** авылы 29 сентябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының 29.03.2011 № 14 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының “Күңгәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (29.08.2011 № 22, 24.11.2011 № 25, 22.03.2012 № 35, 18.09.2012 № 44, 03.12.2012 № 47, 08.10.2013 № 64, 23.03.2015 № 107, 18.12.2015 № 12, 02.05.2016 № 26, 25.04.2017 № 45/1, 28.08.2017 № 53, 25.04.2018 №71, 21.12.2018 № 87,22.05.2019 № 96, 03.10.2019 № 106, 20.12.2019 № 115, 09.03.2020 №125, 30.10.2020 № 8, 29.01.2021 №15, 01.09.2021 №31, 18.07.2022 № 51, 09.02.2023 №69 үзгәрешләре белән).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И.

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы Күңгәр
авыл җирлеге Советының
29.09.2023 ел № 85 карарына

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге**
**Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **28 статьяның 2.4 пунктындагы 3 абзацта** «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

2. **28 статьяның 2.6 пунктын** түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга «,«Коррупциягә каршы тору турында» гы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләре нигезендә, әгәр федераль конституцион законнарда, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аларга бәйле булмаган шартлар аркасында мондый тыюлар, чикләүләр һәм бурычлар бозылган очраклардан тыш”;

3. **28 статьяның 2.9 пунктын** үз көчен югалткан дип танырга;

4. **38 статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:
“12. Депутатның муниципаль берәмлек вәкиллекле органының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез булмавы.»;

5. **49 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацында** «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр; «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның 82.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр;», «муниципаль районның сайлау комиссиясе;» сүзләрен төшереп калдырырга;

6. **49 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында** «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. **49 статьяның 3 пунктын** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:
“3. Җирлек советы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләргә тиеш.”;

8. **66 статьяның 9 пунктында** «һәм мәдәният» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халыклары (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)» сүзләрен өстәргә.